КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 244

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказын формалаштыру тәртибе турында» 2010 ел, 25 июнь, 519 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказын формалаштыру тәртибе турында» 2010 ел, 25 июнь, 519 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 1 июль, 528 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1028 нче; 2018 ел, 21 декабрь, 1205 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исеменә «дәүләт граждан хезмәткәрләрен» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне» сүзләрен өстәргә;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт заказы турында» 2008 ел, 22 ноябрь, ПУ-599 нчы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировка мәйданчыклары системасы турында» 2018 ел, 18 август, ПУ-574 нче указларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктта:

икенче абзацка «дәүләт граждан хезмәткәрләрен» сүзләреннән соң «һәм

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларын фәнни-методик, уку-укыту-методик һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүгә ел саен тотып калына торган акчаның минималь күләмен тиешле елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказын тормышка ашыру өчен күздә тотылган акчаның 5 проценты күләмендә билгеләргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.1 нче пункт өстәргә:

«2.1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына муниципаль заказны формалаштырганда бу карарның 1 нче пункты белән расланган икътисадый нормативларны куллануны тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларын тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү минималь кыйммәтенең икътисадый нормативларын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2010 ел, 25 июнь, 519 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 244 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларын тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү минималь кыйммәтенең икътисадый нормативлары

| Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары категорияләре | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республика-сында муници-паль хезмәт вазыйфалары төркемнәре | Һөнәри үстерү чаралары төрләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 кеше-сәгать кыйммәте, сум | | | | 1 кеше-көн кыйммәте, сум |
| | | яңадан һөнәри әзерләү, квалификация күтәрү | | | Татарстан Республикасы-ның дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республика-сында муниципаль хезмәт-кәрләрнең Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында стажировкасы | Россия Федерациясе территория-сеннән читтә алына торган өстәмә һөнәр белеме |
| | | Татарстан Республика-сының дәүләт граждан хезмәтеннән һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән аерылып | Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтеннән һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән өлешчә аерылып | Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтеннән һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән аерылмыйча | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Җитәкчеләр | югары | 164,1 | 164,1 | 164,1 | 236 | 17 433,8 |
| Ярдәмчеләр (киңәшчеләр), белгечләр | югары | 134,4 | 134,4 | | 236 | 17 433,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Җитәкчеләр, ярдәмчеләр (киңәшчеләр), белгечләр, тәэмин итүче белгечләр | баш, төп | 134,4 | 134,4 | | 236 | 13 308,8 |
| Белгечләр, тәэмин итүче белгечләр | өлкән | 134,4 | | | | 13 308,8 |
| Тәэмин итүче белгечләр | кече | 107 | | | | 13 308,8 |